ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 258 от «15» 07 2020 г.

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2016 нчы
елның 12 нче июлендә кабул ителгән
826 нчы карарына үзгәрешләр
кертү турында (22.03.2019 ел,
93нче карардагы үзгәрешләр белән)

Мамадыш районы прокуратурасының 2020 елның 19 июнендәге 02-08-02-2020 санлы протесты, Россия Федерациясенең «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 12 июлендә кабул ителгән 826 нчы карары (22.03.2019 ел, 93 нче карардагы үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру буенча административ регламентының 25 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Планлаштырылган тикшерүне тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү өчен нигез булып түбәндәгеләрдән соң 1 ел узу тора:

1) Дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган хәбәрнамәгә туры китереп, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;

1.1) социаль файдаланудагы беренче наем йортының социаль файдаланудагы наем йортлары муниципаль реестрында эшчәнлекләре тикшерелергә тиешле зат булган социаль файдаланудагы беренче наем йортын социаль файдаланудагы наем йортлары муниципаль реестрында исәпкә кую;

2) юридик затка, шәхси эшмәкәргә карата соңгы планлы тикшерүне үткәрү тәмамлануы;

3) коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) куллану нормативларын билгеләү һәм үзгәртү.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 нче елның 4 нче апрелендә кабул ителгән 308 нче номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

0000010549

3. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының гомуми бүлегенең җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә секторына әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль районының http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И. М. Дәрҗеманов